**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

2017 ел, 9 июнь

№ 367

г. Казань

Чирмешән муниципаль районында жир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татнефтепром» акционерлык җәмгыятенең Чирмешән муниципаль районында урнашкан, «Татнефтепром» акционерлык җәмгыяте милкендә булган 1,0336 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә, җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында, сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:41:160203:153 | 0,6704 |
| 16:41:160203:154 | 0,3632 |
| Барлыгы | 1,0336. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\367.docx